**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**

**Арча муниципаль берәмлеге**

**Арча шәһәре**

**Башкарма комитеты**

**422000, ТР, Арча ш., мәйдан Советы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Исполнительный комитет**

**города Арск**

**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

# КАРАР

**« 29 » сентябрь, 2021 ел** **№ 123**

**Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Башкарма комитетының 17.08.2021 ел, №97 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча шәһәр башкарма комитеты карар бирә:

1. «Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Башкарма комитетының 17.08.2021ел, №97 карары белән расланган агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «авария хәлендәге агачлар, куаклар турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «яки гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә, аеруча кирәк булганда (авария хәлендәге агачлар), яшел үсентеләрне юк итү зарурилыгы расланмау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында. «(авария-торгызу эшләре үткәрүгә яки аеруча кирәк булганда яшел үсентеләрне юк итүгә бәйле очраклардан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 2.8.4 пунктында. «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «шулай ук авария-торгызу эшләре үткәрү өчен яисә яшел үсентеләрне юк итү өчен яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта (авария хәлендәге, агачның аву куркынычын бетерү өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 3.5.2.3 пунктны төшереп калдырырга;

1.9. 3.5.5 пунктында. «;мөрәҗәгать итүченең авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә бик кирәк булганда яшел үсентеләрне юк итү өчен муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (авария хәлендәге, агачның аву куркынычын бетерү өчен) – ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.10. Регламентның 2 нче кушымтасында «авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Арча шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Ф.Касыймов